**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 8 маендагы 1589 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 26 декабрендәге 4609 номерлы**
**«Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә**
**түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең**
**административ регламентын раслау турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы «“Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон кабул ителү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 декабрендәге 4609 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 252 номерлы, 2023 елның 29 мартындагы 924 номерлы, 2024 елның 9 августындагы 3332 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8.2.1 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3) җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән коммерциягә нигезләнмәгән бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен каралган булса) яисә коммерциягә нигезләнмәгән бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган, федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлеген

беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алуга яисә Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга хокукы булган гражданинның (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык кишәрлеге булса), шулай ук гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре хуҗалары (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса) мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, мондый гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге коммерциягә нигезләнмәгән бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә ясалган булу»;

1.2. 2.8.2.1 пунктының 13 пунктчасында:

1.2.1. «хуҗалык» сүзеннән соң «торак пунктлары чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

1.2.2. «яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 2.8.2.1 пунктының 16 пунктчасында «чик» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**